# ҮЗ ХАЛКЫН ДАНЛАГАН ТАТАРЛАР:
# КАЮМ НАСЫЙРИ

**Каюм Насыйри калдырган мирас белән танышу өчен платформа һәм кыстыргычлар**

**Проектны башкаручы:**
**Кәримова Лилия Рамил кызы,**
«Адымнар – Казан» мәктәбенең
11 нче сыйныф укучысы

**Фәнни җитәкче:**
**Ханнанов Рамил Гомәр улы,**
«Адымнар – Казан» мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# Проектның максатлары һәм бурычлары.

**Максат:** Каюм Насыйриның фәнни-мәдәни мирасын саклау һәм актуальләштерү өчен заманча белем бирү платформасын һәм кыстыргычлар булдыру.

**Бурычлар:**

1. Галимнең биографиясе һәм эшчәнлеге буенча мәгълүмат җыю.
2. Фото һәм видеоматериаллар җыю.
3. Сайт структурасын эшләү: гомуми мәгълүмат, бүлекләр, адаптив навигация.
4. Интерфейс дизайнын ясау.
5. Кыстыргычлар дизайнын ясау.
6. Кыстыргычларны бастырып чыгару.

## КАЮМ НАСЫЙРИ ТҮБӘНДӘГЕ ФӘННӘР БУЕНЧА ХЕЗМӘТЛӘР АВТОРЫ. САЙТ ҺӘМ КЫСТЫРГЫЧЛАР ӘЛЕГЕ ЭШЧӘНЛЕК ТӨРЛӘРЕНӘ НИГЕЗЛӘНГӘН.

- Лексикография ("Лөгать китабы", "Ләһҗәи татари")
- Фонетика һәм грамматика ("Кавагыйд китабет»)
- Тарих, этнография, фольклор
- Табигать фәннәре ("Гөлзар вә чәмәнзар")
- География
- Әдәбият ("Фәвакиһелҗөләса фил әдәбият" - беренче татар энциклопедиясе)
- Педагогика (арифметика, геометрия,
- география дәреслекләре)
- "Казан календаре" календарен нәшер иткән (1871-1897)



# САЙТНЫҢ ТӨЗЕЛЕШЕ




**Беренче биттә Каюм Насыйриның фотосы һәм бүлекләр менюсы тәкъдим ителгән.**

**Бу биттәге менюда галимнең эшчәнлек төрен сайларга яки аскарак төшеп видеоролик карарга мөмкин.**

# ВИДЕОРОЛИК

Алга таба «Адымнар» күптелле мәгариф комплексы укытучылары Рамил Ханнанов һәм Нариман Фәхрисламов «Ватаным Татарстан» газетасы оештырган «Каюм бабай дәресе» конкурсына төшергән видероликны карарга була.

Каюм Насыйри | Язучы | Географ | Биолог | Аш-су остасы | Тел галиме | Сүз остасы




«Ватаным Татарстан» газетасы оештырган «Каюм бабай дәресе» конкурсының «Каюм Насыйри эзләреннән» номинациясенә укытучылар һәм тәрбиячеләр, Каюм Насыйри хезмәтләрен файдаланып, билгеле бер чара уздырырга һәм ул чарадан видеоязма әзерләргә тиеш иде. Бу юнәлештә җибәргән иҗат эшләре арасында «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл» күптелле мәгариф комплексы укытучылары Рамил Ханнанов һәм Нариман Фәхрисламов – җиңүчеләрнең берсе. Әлеге видеоязманы сезгә дә тәкъдим итәбез. Тулырак укырга

# БҮЛЕКЛӘР

Алдагы биттә Каюм Насыйри мавыккан фәннәр һәм бүлекләргә күчү сылтамалары тәкъдим ителә. Бу төймәләргә басып, кирәкле бүлеккә эләгергә мөмкин.






# Бүлекләрдә Каюм Насыйри хезмәтләре турында мәгълүмат һәм фотолар бирелгән.

## Язучы

**Каюм Насыйриның татар әдәбиятына керткән өлеше шактый зур.**

Әдип - "Әбүгалисина кыйссасы", "Кырык вәзир", "Әхлак рисаләсе", "Тәрбич китабы" һ.б. әсәрләрнең авторы. Каюм Насыйри үз әсәрләрендә гореф-гадәтләр, традицияләр, әхлак, иман, гаилә мөнәсәбәтләре, бала тәрбиясе мәсьәләләрен яктырта. Уңай әхлакый сыйфатларны галим укучы өчен үрнәк итеп куя, ә кешенең рухи үсешенә комачаулый торган сыйфатларны, киресенчә, тәнкыйтьләп фаш итә. Әсәрләрнең язылганнынан соң ике гасырга якын вакыт узувына карамастан, аларның эстетик әһәмияте әле дә үз кыйммәтен югалтмый.




## Географ

**Каюм Насыйри – Казан губернасының беренче картасы, Россия мәчетләрендә кыйбланы төгәл билгеләү картасы һ.б. дистәләгән карталар авторы**

Каюм Насыйри – казанышлары Россия фәнни җәмәгатьчелеге тарафыннан танылган беренче татар этнографы һәм географы. Казан губернасының тәүге географик картасында ул мөселман мәчетләренең төп урыны – михрабның төгәл билгеләнешен ачыклауны максат итеп куйган. Каюм Насыйри әлеге картасында Евразия кыйтгасының шактый өлеше өчен, шулай ук Көнбатышта Санкт-Петербургтан алып Көнчыгышта Көньяк Кытай диңгезе озынлыгына кадәр мәчетләрнең кыйблага дөрес юнәлешен күрсәтә.



## Тел галиме

«Татар теле ул – урам теле, ломовойлар теле, әдәби гыйльми тел булырга сәләте юк аның», дигән карашлар яшәгән заманда, Каюм Насыйри халкыбызның туган телен ялкынлы чыгышлар белән яклап чыга: «Ялган, яла бу! Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел. Бүтән телләрдән бер дә ким түгел, эшләмәгәнлек сәбәпле генә ул шулай артта калган». Каюм Насыйри татар теленең фән теле була алуын, моңа аның тулы хакы һәм мөмкинлекләре барлыгын исбат итә.

Каюм Насыйри татар лексикографиясенең нигезен салучы. Ул - "Лөгать китабы" һәм "Ләһҗәи татари"ның авторы. «Ләһҗәи татари» аңлатмалы сүзлегенә кереш сүзендә Каюм Насыйри милли тел нормаларын эшләүнең авырлыгын болай сурәтли: «Безнең телне моңарчы беркем дә фән теле буларак өйрәнмәгәнлектән, ул йокы хәлендә озак булган һәм артта калган. Мин, телебезгә утыз биш ел хезмәт итеп, бик аз нәтиҗәләргә ирештем. Күпме тырышсам, шулкадәр газаплар да күрдем. Үз милләтемне "татар" дип атадым - кайберәүләргә ошамады; телебезне "татар теле", дидем, шулай ук кабул итәргә теләмәделәр».



## Биолог

Каюм Насыйри дарулар кулланмаган. Ул гомер буе дару үләннәре җыйган, шулар белән үзе дә, башкаларны да дәвалаган. Үзенең тәҗрибәсен "Гөлзар вә чаманзар" ("Чәчәкләр һәм үләннәр") китабында тасвирлаган. Бу китабында галим Россия территориясендә үскән 192 үсемлекнең үзлекләрен, 155 авыруны һәм аларны үләннәр ярдәмендә дәвалау ысулларын җентекләп тасвирлаган.




## Аш-су остасы

Каюм Насыйри татар ашлары буенча да кыйммәтле эшләр язган. Ул традицион татар ашларының рецептларын җыйган, аларның әзерләү ысулларын детальләп тасвирлаган.

**Каюм Насыйридан алма күпертмәсе рецепты:**

Ун алманы юка гына тура. Камыр яса: биш йомырка сыт, ике кашык май сал, бик яхшы тугла, ике кашык вак шикәр сал, бер стакан каймак сал, он салып из – камыр яса, бик куе булмасын, кашык белән алырга мөмкин булсын. Табаңны яхшылап кыздыр, табага май сал. Кашык белән камырыңны алып, өстенә бер ике алма куй, табага сал.

Мөрәбба белән аша.



## Сүз остасы

**Гасырлар хикмәте: Каюм Насыйриның канатлы гыйбарәләре**

> *Без - татарлар, телебез - татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул».*

> *Әй угыл, мал табуның юллары бик күптер. Нинди генә юл булмасын, малны хәләлдән табу фарыздыр. Хәләлдән килгән мал – тотрыклы буладыр. Хәрәм мал исә адәмгә йокмыйдыр, тиз кулыңнан китәр, җаваплылыгы һәм авырлыклары гына сиңа калыр. Әмма хәләлдән килгән малыңны саклап тот, хәрәм җиргә сарыф итмә. Малны саклау малны табу һәм җыюңан авыррак. Саклап тота белмәгәннәре сәбәпле, никадәр байлар малсыз калдылар».*

> *Бәс, әй угыл, нәфсең симергән саин, ул сине һәлакәткә тартыр. Дөньяда баһадир шул кешедер ки, — нәфесен җиңәр».*

# Соңгы бит «Каюм Насыйри иseme мәңгелек» дип атала.
# Бу биттә фотосурәтләр галереясы тәкъдим ителгән.

Сайтка сылтама: *https://universal-legacy-initiative--preview.poehali.dev*















**Сайт – безнең проектның бер өлеше генә. Моннан тыш, без дәреслекләр өчен кыстыргычлар ясадык. Кыстыргычтагы эшчәнлек төренә карап, аны төрле мәктәп предметлары өчен кулланырга мөмкин. Мәсәлән, "Каюм Насыйри - географ" дип аталганын география дәреслегенә кыстырырга була.**

адымнар
мультилингвальная школа

# ҮЗ ХАЛКЫН ДАНЛАГАН ТАТАРЛАР:

# КАЮМ НАСЫЙРИ

**Әлеге проект кысаларында без куелган бурычларны үтәдек һәм татар мәдәниятен саклау һәм үстерүгә үз өлешебезне керттек.**

**Безнең онлайн-платформада Каюм Насыйриның эшчәнлек төрләре һәм хезмәтләре белән танышырга мөмкин. Кыстыргычлар бу белемнәрне гадәти тормышка кертергә булышачак. Әлеге кыстыргычлар ярдәмендә китапны ачка галимнең эшчәнлеге турында искә төшерергә була.**